**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлеге составына керүче Сәмәкәй авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**КАРАР**

26 октябрь 2024 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә **2024 елның 26 октябрендә** түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Сәмәкәй авыл җирлегенең Сәмәкәй авылы территориясендә 2025 елда балигъ булган, Сәмәкәй авыл җирлегенең Сәмәкәй авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I һәм II группа инвалидларга һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарына, ялгыз карт гражданнарга һәм көндезге формада укучы студентларга, күп балалы гаиләләргә бер тапкыр түләүне киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган Сәмәкәй авыл җирлеге территориясендә теркәлгән гражданнарны һәм гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взносларны түләүдән азат итәргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләрне:

-торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (чокыр ремонтлау, юллар төзү, вак таш сатып алу, махсус техника хезмәтләре);

- урам яктырту эшләрен башкару (электр материаллары сатып алу, су башнясына электр тапшыру линияләрен монтажлау, алмаштыру һәм урнаштыру);

хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме

“ӘЙЕ” “ЮК”.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы **228** кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – **117** кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы **117** кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенында катнашучы **0** кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлеге Сәмәкәй авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип таныргa.

2. «2025 елда яшәү урыны буенча Сәмәкәй авыл җирлеге Сәмәкәй авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I һәм II группа инвалидларга һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарына, ялгыз карт гражданнарга һәм көндезге формада укучы студентларга, күп балалы гаиләләргә бер тапкыр түләүне киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган Сәмәкәй авыл җирлеге территориясендә теркәлгән гражданнарны һәм гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взносларны түләүдән азат итәргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләрне:

-торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (чокыр ремонтлау, юллар төзү, вак таш сатып алу, махсус техника хезмәтләре);

- урам яктырту эшләрен башкару (электр материаллары сатып алу, су башнясына электр тапшыру линияләрен монтажлау, алмаштыру һәм урнаштыру); **мәсәләсе буенча карарны кабул ителгән дип таныргa**.

3. Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлеге Сәмәкәй авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

4. Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлеге Сәмәкәй авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сәмәкәй авыл җирлеге Башлыгы И.М.Усманов

СЕМЕКЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ